# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Олы Ачасыр авыл җирлегенең Бишбатман авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

**2023 елның 25 марты** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 7 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 25 мартның 10 сәгать 00 минутында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде: «Сез Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлегенең Бишбатман авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләренә 2023 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы «2024 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлегенең Бишбатман авылы торак пунктында гражданнарның үзара салымнарын кертү турында»гы карарына һәм 2023 елның 24 ноябрендәге 2 номерлы «2024 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлегенең Бишбатман авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы карарына үзгәрешләр кертүгә ризамы?:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (асфальт сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эш өчен түләү, смета документациясен әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру)».

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыен катнашучылары исемлегенә гражданнар җыенының 32 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 22 кеше, бу 68,75% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленгән:

«ӘЙЕ» позициясе өчен гражданнар җыенының 22 катнашучысы тавыш бирде, «КАРШЫ» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлегенең Бишбатман авылында гражданнарның җыенын кабул итү нәтиҗәләре – чын.

2. Гражданнар җыенына чыгарылган мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. 2024 елда алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (асфальт сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эш өчен түләү, смета документациясен әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру)».

4. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Олы Ачасыр авыл җирлеге мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Ачасыр авыл жирлеге башлыгы ______ И.М. Саттаров
(имза)